| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СОВЕТ ПСЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПЕСӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |

---

**Р Е Ш Е Н И Е** **К А Р А Р**

**24 октябрь 2024 ел** **№ 132**

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 3 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Кодексы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Песәй җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге Советының 2023 елның 15 февфралендәге 71 номерлы карары белән расланган Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәнең 4.1 бүлеге 3 пунктының 5 пунктчасын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) белем һәм квалификация турында документ;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http://mendeleevsk.tatarstan.ru «Песәй авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

Песәй авыл җирлеге Советы рәисе В.И. Мөхәммәтгалеев